# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 18 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә сәгать 13.00 «2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә җыярга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
1) Дружба торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)
2) Ләке авыл җирлегендә "Питрау" бәйрәме өчен призлар, бүләкләр сатып алу;
3) Дружба торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 39 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 26 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
позиция өчен гражданнар җыенында катнашучы 26 кеше тавыш бирде; каршы позиция өчен _0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны танырга: «2023 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары

студентларыннан тыш, ризамы, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

- Дружба торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Ләке авыл җирлегендә "Питрау" бәйрәме өчен призлар, бүләкләр сатып алу;
- Дружбасы торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлегенең информацион стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _ _ _ _ _ _ Шәрипова Л. И.